РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» август 2026 г. г. Альметьевск № 37

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында» 2023 елның 11 августындагы 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында» 2023 елның 11 августындагы 116 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2024 елның 26 июнендәге 148 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләрен «Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда»сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарга кушымтада:

а) 2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре, әлеге Нигезләмәнең 3 статьясында каралган очраклардан тыш, яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының (алга таба - шәһәр Советы) тулы хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән башлана һәм туктатыла.»;

б) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип тану;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан ителү;

5) аңа карата судның гаепләү хөкеменең законлы көченә керүе;

6) даими яшәү урынына Россия Федерациясеннән читкә чыгу;

7) Россия Федерациясе гражданлыгының туктатылуы яисә чит дәүләт гражданлыгының (гражданлыгының) яисә яшәүгә рөхсәтенең яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документының булуы;

8) шәһәр Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

9) хәрби хезмәткә чакыру яисә аны алмаштыручы альтернатив граждан хезмәтенә юллама;

10) чит ил агенты статусын алу;

11) «Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән башка очраклар.

Депутатның вәкаләтләре алты ай рәттән шәһәр Советының барлык утырышларында җитди сәбәпләрсез депутат булмаганда шәһәр Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

в) 5 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «даими булмаган нигездә» сүзләрен «, кагыйдә буларак, даими булмаган нигездә» сүзләренә алмаштырырга»;

г) 12 статьяның 5 өлешендәге беренче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

д) 20 статьяның 2 өлешендә «сакланып калу» сүзен «эш бирүче тарафыннан сакланып калып эшләүдән азат ителүе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча шәһәр Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы — Г.М. Хәбутдинова